Татарстан җөмһүрияте Актаныш муниципаль районы
Актанышбаш авыл җирлеге Советы

**КАРАР**
**№ 22**

**РЕШЕНИЕ**
**«13» сентябрь 2018 ел**

**Татарстан җөмһүрияте Актаныш муниципаль районы Актанышбаш авыл җирлеге составына керүче гражданнарның җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибен раслау Нигезләмәсе**

06.10.2003 елның №131–ФЗ санлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми нигезләре турында»гы Федераль Законның 25.1 маддәсен, 28.07.2004 елның № 45-ЗРТ санлы «Татарстан җөмһүриятендә җирле үзидарә турында»гы Татарстан җөмһүрияте Законының 35 маддәсен һәм Татарстан җөмһүрияте Актаныш муниципаль районы «Актанышбаш авыл җирлеге» муниципаль берлеге Уставының 25.1 маддәсен тормышка ашыру максатында, Актаныш муниципаль районы Актанышбаш авыл җирлеге Советы

**карар кылды:**

1. Татарстан җөмһүрияте Актаныш муниципаль районы Актанышбаш авыл җирлеге составына керүче гражданнарның җыенын әзерләү һәм үткәрү Нигезләмәсен кушымтага туры китереп расларга.

2. Бу карар Татарстан җөмһүрияте рәсми хокукый хәбәрләр порталында һәм Актаныш муниципаль районы Актанышбаш авыл җирлегенен рәсми сайтында урнаштырылганнан соң үз көченә керә.

3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан җөмһүрияте Актаныш муниципаль районы Актанышбаш авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Совет рәисе, Актанышбаш
авыл җирлеге башлыгы Л.Г.Хайдарова